Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР

2021 елның 9 феврале № 7/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге Советының
2019 елның 5 июнендәге 60/2 номерлы
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт
турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы һәм «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 21 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Чистай муниципаль районының Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2019 елның 5 июнендәге 60/2 номерлы Түбән Кондрата авыл җирлеге советы карары белән расланган Чистай муниципаль районының «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«22. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турында белешмәләр шәхси эшкә һәм хезмәт кенәгәсенә (булган очракта) кертелә.»;

1.2. 11 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

1.3. 13 статьяның 3 пунктында:
4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән;»

6 пунктчада «Мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында, Россия Федерациясе Пенсия фонды мәгълүмат ресурсларында саклау өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм авыл җирлеге халкының массакүләм җыелу урыннарында, игълан итү стендларында һәм такталарында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кондрата авыл җирлеге
башлыгы С.В. Васильев